ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының дүртенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының дүртенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасын раслау турында.
2. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 5-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 6-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 13 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 596-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 71 статьясына үзгәреш кертү хакында» 686334-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе җинаять-үтәү системасы хезмәткәрләренең балаларына югары белем бирү мәгариф оешмаларына керүгә өстенлекле хокук бирү өлешендә).

7. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының җирле үзидарә органнарына хокукый ярдәм күрсәтү максатларында алар белән хезмәттәшлеген оештыру турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 4 октябре
№ 9-VII ДСП